БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» 07 2026 ел № 214

2026 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләренә торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең иң чик индексы күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясының 4 өлеше, шулай ук Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләренә торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2018 елның 6 апрелендә расланган 213/пр номерлы боерыгы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 2026 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләренә торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең иң чик (максималь) индексын 13 процент күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов